КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 май г.Казань № 436

Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану тәртибен һәм шартларын раслау хакында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 4 статьясындагы 4 пункты, 27 статьясы, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә кайбер мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану тәртибен һәм шартларын расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану кагыйдәләрен раслау хакында» 2016 ел, 3 октябрь, 708 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 12 май, 436 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары
турында геологик мәгълүматны файдалану
тәртибе һәм шартлары

1. Бу Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчасы исәбеннән җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан алынган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматның, шулай ук «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 27 статьясындагы ундүртенче өлешендә күрсәтелгән сроклар чыкканга кадәр үз акчасы исәбеннән җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата алынган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматның (алга таба – җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат) иясе булып тора.

3. Татарстан Республикасы исеменнән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматның иясе хокукы Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Физик һәм юридик затлар (алга таба – заявка бирүчеләр) җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматтан файдаланучы булырга мөмкин.

5. Заявка бирүче җир асты байлыклары турындагы мәгълүматтан бары аны алганда күрсәтелгән максатларда гына җир асты байлыклары турында, мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау турында, дәүләт сере һәм коммерция сере турында, шулай ук җир асты байлыклары турында мәгълүмат экспорты хакында законнар таләпләре нигезендә файдалана.

6. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат түбәндәге ысуллар белән бирелә:

а) заявка бирүчене эчтәлеге белән таныштыру юлы белән, өземтәләр һәм күчермәләр алу хокукы белән кәгазьдә;

б) заявка бирүчене электрон документлар һәм материаллар белән таныштыру юлы белән, заявка бирүченең электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларына күчерү өчен мәгълүмат документларының һәм материалларның электрон сурәтләрен эшләү хокукы белән электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында.

7. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат заявка бирүчеләргә бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалануга бирү хакында Вәкаләтле органга җибәрелә торган заявка (алга таба – заявка) нигезендә бирелә.

8. Заявкада түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) заявка бирүче турында мәгълүмат (юридик зат өчен – исеме, оештыру-хокук формасы, урнашу урыны; физик зат өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), паспорт сериясе һәм номеры; урнашу урыны, телефоны, электрон почта адресы (булганда));

б) геологик мәгълүматны алу максаты (җир асты байлыкларыннан файдалану, дәүләт контракты буенча эшләр башкару, фәнни, уку һәм башка максатлар);

в) рәсми соратыла торган мәгълүмат исемлеге (рәсми соратыла торган мәгълүматның төрен һәм аның эчтәлеге белән таныштыру ярдәмендә мәгълүмат документлары һәм материаллар (фактографик мәгълүматтан тыш) өземтәләрен һәм күчермәләрен алу хокукы белән аны бирү ысулын күрсәтеп, геологик мәгълүмат фондлары каталоглары нигезендә);

г) датасы, имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), мөһер (булганда);

д) дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләргә кертелгән җир асты байлыклары турында мәгълүматтан файдалануга рөхсәт булуны раслый торган документ реквизитлары – дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләргә кертелгән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны алу өчен мөрәҗәгать иткәндә.

9. Заявка кәгазьдә яки, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, гариза бирүченең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куелган электрон документ рәвешендә бирелә.

10. Заявка Вәкаләтле орган тарафыннан кергән көнне теркәлә.

11. Вәкаләтле орган заявка теркәлгән көннән 20 эш көне эчендә җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат белән танышу яки җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны үз эченә алган документлар һәм материаллар күчермәләрен алу вакыты һәм урыны турында яисә җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат бирүдән баш тарту хакында заявка бирүче адресына белдерү кәгазе җибәрә.

12. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

б) заявканың бу Тәртипнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

б) гариза бирүченең таратылуы чикләнгән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматтан файдалануга рөхсәте булмау (таратылуы чикләнгән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны биргәндә);

в) гариза бирүченең дәүләт серен тәшкил итә торган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматтан тиешле форма буенча файдалануга рөхсәте булмау (дәүләт серен тәшкил итә торган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны биргәндә).

Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат бирүдән баш тарту өчен нигез булган сәбәпләр бетерелгәннән соң, гариза бирүче вәкаләтле органга заявка белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

13. Заявка бирүче аңа бирелгән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны, вәкаләтле орган ризалыгыннан башка, өченче затларга бирергә хокуксыз.

14. Заявка бирүченең җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү түбәндәге документлар күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла:

1) заявка бирүченең шәхесен раслый торган документ (заявка бирүче физик зат булган очракларда);

2) заявка бирүче исеменнән затның эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ (юридик зат йә физик зат вәкиле заявка бирүче булган очракларда).

15. Геологик мәгълүмат бирелгән өчен акча алынмый.

Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалану тәртибенә һәм шартларына кушымта

Форма

Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны файдалануга бирүгә заявка

1. Заявка бирүче турында мәгълүмат: ________________________________________
(юридик зат өчен – исеме, оештыру-хокук формасы,
________________________________________________________________________________
урнашу урыны, электрон почта адресы (булганда); физик зат өчен – фамилиясе, исеме,
________________________________________________________________________________
атасының исеме (булганда), паспорт сериясе һәм номеры; урнашу урыны, телефоны,
________________________________________________________________________________
электрон почта адресы (булганда))

2. Геологик мәгълүматны алу максаты: ______________________________
(җир асты байлыкларыннан
________________________________________________________________________________
файдалану, дәүләт контрактлары буенча эшләр башкару, фәнни, уку һәм башка максатлар)

3. Рәсми соратыла торган мәгълүмат исемлеге (бирүнең төрен һәм ысулын күрсәтеп, геологик мәгълүмат фондлары каталоглары нигезендә):
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

4. Таратылуы чикләнгән мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге _______________
________________________________________________________________________________
(рөхсәт итә торган документларның күчермәләрен теркәп)
__________________________________________________________________ нигезендә бар

5. Таратылуы чикләнгән мәгълүматны таратмауны һәм, вәкаләтле органның ризалыгыннан башка, өченче затларга бирмәүне үз өстебезгә алабыз.

________________________ ___________________ ______________________________
(дата) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Мөһер (булганда)

______________________________